| СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ |
|---|---|---|

РЕШЕНИЕ КАРАР

18.11.2020 ел Алабуга шәһәре № 26

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлегенең бюджеты турында» 2019 елның 17 декабрендәге 432 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Алабуга муниципаль районында бюджет процессы турындагы Нигезләмә нигезендә һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 83 һәм 86 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының бюджеты турында» 2019 елның 17 декабрендәге 432 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның

*1 өлешендә:*

1 нче пунктта: «1 816 758,8» саннарын «1 831 836,8» саннарына алмаштырырга;

2 нче пунктта «1 891 022,9» саннарын «1 916 100,9» саннарына алмаштырырга;

3 нче пунктта «74 264,1» саннарын «84 264,1» саннарына алмаштырырга;

*3 өлешендә:*

1 нче кушымтаның 1 нче таблицасын «2020 елга район бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары» яңа редакциядә бәян итәргә;

2) 3 статьяда:

2 нче кушымтаның 1 нче таблицасын «2020 елга район бюджетының фаразланган керемнәре күләме» үзгәрешләр кертү өлешен бәян итәргә;

3) 6 статьяда:
4 нче кушымтаны «Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеге» үзгәрешләр кертергә һәм тулыландырырга;

4) 7 статьяда:
6 нчы кушымтаның 1 нче таблицасын «2020 елга район бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы» яңа редакциядә бәян итәргә;
7 нче кушымтаның 1 нче таблицасын «Район бюджеты ассигнованиеләрен 2020 елга бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлү» яңа редакциядә бәян итәргә;
8 нче кушымтаның 1 нче таблицасын «Район бюджетының бюджет ассигнованиеләрен 2020 елга бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары (муниципаль программалар Һәм эшчәнлекнең программалаштырылмаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлү җирлек бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бүлү» яңа редакциядә бәян итәргә;

5) 15 статьяда:
13 нче кушымтаны «2020 елга район бюджетына җирлекләр бюджетларыннан тапшырыла торган бюджетара трансфертлар» яңа редакциядә бәян итәргә;

6) 16 статьяда:
14 нче кушымтаны «2020 елга җирлекләр бюджетларына район бюджетыннан тапшырыла торган бюджетара трансфертлар» яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны икътисади үсеш, бюджет, салымнар, тариф сәясәте һәм эшкуарлыкка ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.
3. Әлеге карар массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми бастырылырга тиеш.

Совет Рәисе Р.М. Нуриев